ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы
боерыгы белән расланды
29.02.2021
№29-ОД

**Нигезләмә**
**яшьләр инициативаларының республика конкурсы турында**
**«Без энергия нәтиҗәлелеген сайлыйбыз-2021»**

Әлеге Нигезләмә «Без энергия нәтиҗәлелеген сайлыйбыз» яшьләр инициативаларының республика конкурсында (алга таба – Конкурс) катнашу кагыйдәләрен, аларны оештыру һәм уздыру тәртибен билгели.

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Конкурс энергия нәтиҗәлелеге һәм энергияне сак тоту өлкәсендә фәнни-техник һәм инновацион эшчәнлекне активлаштыруга, гомуми белем бирү оешмалары укучыларының, һөнәри белем бирү оешмалары һәм югары белем бирү мәгариф оешмалары студентларының һәм аспирантларының фәнни-техник һәм инновацион эшләнмәләрен ачыклауга һәм аларга ярдәм итүгә, энергияне сак тоту һәм энергия ресурсларының нәтиҗәлелеген арттыру өлкәсендә икътисадый һәм норматив-хокукый прогрессны үстерүгә юнәлдерелгән.

1.2. Конкурсны оештыручылар – Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Энергия саклау технологияләре үзәге» ДАУ, «Казан дәүләт энергетика университеты» югары һөнәри белем бирү ФДБМУ.

1.3. Конкурста катнашуга заявка бирү вакытына **16 яшьтән 30 яшькә кадәрге** Россия гражданнары, гомуми белем бирү оешмаларының өлкән сыйныф укучылары, һөнәри белем бирү оешмалары һәм югары белем бирү оешмалары студентлары һәм аспирантлары чакырыла.

1.4. Конкурс **2021 елның 1 мартыннан 31 мартына кадәр** уздырыла. Конкурска материаллар 2021 елның 31 мартына кадәр (шул көнне дә кертеп) кабул ителә.

1.5. Конкурс турында мәгълүмат Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы http://mpt.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы http://mon.tatar.ru, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Энергия саклау технологияләре үзәге» ДАУ https://cet.tatarstan.ru, «Казан дәүләт энергетика университеты» югары һөнәри белем бирү ФДБМУ https://www.kgeu.ru һәм

энергия ресурслары нәтиҗәлелеге һәм экология буенча Татарстан халыкара форумы (алга таба - ТЭФ) http://tef.tatar.tatar.ru сайтларында урнаштырыла.

1.6. Конкурс эшләре рус яки татар телендә башкарылырга мөмкин.

Конкурста җиңүчеләр исемлеге Энергия ресурсларының нәтиҗәлелеге һәм экология буенча Татарстан халыкара форумының рәсми сайтында басыла: http://tef.tatar/.

1.7. Конкурс катнашучылар өчен түләүсез нигездә уздырыла һәм теркәлү өчен, шулай ук башка кертемнәр алуны күз алдында тотмый.

## 2. Конкурсның максатлары һәм бурычлары

**2.1. Конкурсның максатлары:**

2.1.1. Энергия ресурсларының нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән инновацион эшчәнлекне тормышка ашырырга омтылган талантлы яшьләрнең инновацион, иҗади, технологик һәм техник эшләнмәләрен ачыклау.

2.1.2. Энергия ресурсларының нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән яшьләрнең фәнни-техник һәм инновацион эшчәнлеккә игътибарын җәлеп итү.

2.1.3. Яшьләрне энергияне сак тотучы тормыш рәвеше культурасына, энергияне нәтиҗәле тотуга һәм ресурсларның барлык төрләренә сакчыл мөнәсәбәт культурасын популярлаштыруга җәлеп итү.

2.1.4. Энергия нәтиҗәлелеген һәм энергияне сак тотуны стимуллаштыру һәм популярлаштыру, инновацион фәнни-тикшеренү, практик әһәмиятле, иҗади эшчәнлекнең абруен күтәрү, җәмәгатьчелек игътибарын энергия нәтиҗәлелеген һәм энергияне сак тотучы тормыш рәвешен үстерүгә җәлеп итү.

**2.2. Конкурсның бурычлары:**

2.2.1. Энергияне сак тоту һәм энергия нәтиҗәлелеге өлкәсендәге бурычларны хәл итүгә юнәлдерелгән фәнни-инновацион идеяләр, проектлар авторларына, талантлы яшьләргә ярдәм итү.

2.2.2. Энергия саклау технологияләре белән кызыксыну формалаштыру.

2.2.3. Энергия ресурсларының нәтиҗәлелеген, энергияне сак тотуны һәм энергетиканы үстерүне арттыруга юнәлдерелгән идеяләрне һәм проектларны популярлаштыру.

## Конкурс номинацияләре

3.1. Конкурс 5 номинация буенча үткәрелә:

<u>Гомуми белем бирү оешмаларының өлкән сыйныф укучылары өчен номинация:</u>

**«Энергия нәтиҗәлелегенә ия кеше - энергия нәтиҗәлелегенә ия җәмгыять».**

Гаилә, сыйныф, мәктәп мисалында энергия нәтиҗәлелеген популярлаштыру өчен бирелә. Энергияне сак тоту кирәклеген ачык күрсәтә һәм гамәли рекомендацияләр бирә торган мәгълүмати продукт уйлап табарга тәкъдим ителә.

Бу листовка, газета, плакат, буклет, презентация, видеоролик яки башка мультимедиа продукт булырга мөмкин.

Студентлар һәм аспирантлар өчен һөнәри белем бирү оешмалары һәм югары белем бирүче мәгариф оешмалары номинацияләре:

**«Энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру буенча иң яхшы инженер-техник карар»:**

– энергия нәтиҗәлелеге һәм энергияне сак тотуга идарә итүнең автоматлаштырылган мәгълүмат системалары;
– кондиционерлау һәм вентиляция;
– җылылык белән тәэмин итү, су белән тәэмин итү;
– электр белән тәэмин итү
– электр энергиясен тапшыру;
– торгызыла торган энергия чыганаклары;
– яктырту системалары;
– әйләнә-тирә мохитне саклау
– энергетиканы үстерүнең инновацион проектлары.

**«Энергияне сак тоту һәм энергия нәтиҗәлелеген арттыру буенча иң яхшы оештыру һәм мәгълүмат чаралары:**

– энергияне сак тоту һәм энергия нәтиҗәлелеге өлкәсендә белем бирү;
– энергетика менеджменты;
– энергия нәтиҗәлелеге өлкәсендә халыкара хезмәттәшлек;
– энергияне сак тоту һәм энергия нәтиҗәлелеге өлкәсендә популярлаштыру.

Конкурсның махсус бүләге:

**«Энергия ресурсларының нәтиҗәлелеге һәм энергияне сак тоту буенча иң оригиналь идея».**

Барлык идеяләр кабул ителә, шул исәптән, бүген чынлыкта тормышка ашырырга ярамаганнары да. Төп критерийлар: яңалык һәм оригинальлек, шулай ук физика һәм логиканың төп законнарына каршылыклар булмау.

3.2. Конкурста катнашуга дәгъва кылучыны күрсәтү гомумбелем бирү оешмасы (мәктәпләр, гимназия, лицей) җитәкчелегенең, һөнәри белем бирү мәгариф оешмасының, шул исәптән югары һөнәри белем бирүнең мәгариф оешмасының үтенечнамәсе нигезендә дә башкарыла.

3.3. Бер кеше бер номинациядә бер эш белән катнаша ала.

3.4. Конкурста катнашу өчен мәҗбүри конкурс документациясен тутырырга кирәк: катнашучының гаризасын, 1 нче кушымта нигезендә конкурс эше паспортын һәм конкурс эшен тәкъдир итү (студентлар һәм аспирантлар өчен номинацияләр, 5-10 слайд, файл форматы - PDF).

3.5. Конкурста катнашучы мәҗбүри конкурс документларына түбәндәге документларны теркәргә мөмкин:

– фотографияләр, иллюстрацияләр (файллар форматы - JPG);

– конкурс эшен гамәлгә ашыру барышын тасвирлаган документлар (файлларның форматы - PDF);

– видеоматериал (материал урнаштырылган YouTube ка актив сылтама);

– отзывларның, рекомендация хатларының, рецензияләрнең, дипломнар, грамоталар, рәхмәт хатларының, эш нәтиҗәләрен кертүне хуплау яисә кертү нияте турындагы хатларның сканирлаштырылган күчермәләре, эш нәтиҗәләренең гамәли әһәмияте турында бәяләмә, массакүләм мәгълүмат чараларындагы публикацияләр (булса ярый, катнашучы карамагында).

Кушымталарның саны һәм күләме чикләнмәгән.

3.6. Гаризаларны һәм кушымта итеп бирелгән конкурс документациясен конкурс комиссиясе бары тик электрон рәвештә түбәндәге почта адресына кабул итә: cetrt@mail.ru - **2021 елның 31нче мартына кадәр**.

## 4. Конкурс эшләренә таләпләр һәм аларны бәяләү критерийлары

4.1. Конкурс эшләре әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымта таләпләре нигезендә рәсмиләштерелә. Конкурста катнашуга конкурс комиссиясе карары буенча тиешле рәвештә бирелмәгән заявкалар кертелмәскә мөмкин.

4.2. Конкурс эшләрен бәяләгәндә эшне бәяләүнең түбәндәге критерийлары исәпкә алына:

- эшнең практик кыйммәте һәм нәтиҗәләрне гамәлгә кертү мөмкинлеге;
- эш нәтиҗәләрен кертүдән икътисадый файда;
- нәтиҗәләр һәм тәкъдимнәрнең нигезлелеге;
- эш темасының актуальлеге һәм фәнни яңалыгы;
- эштә инновацион алымнар булу;
- эшнең иҗади характеры, тикшеренүгә якын килүнең мөстәкыйльлеге, авторның шәхси өлеше;
- чыганакларны сайлап алу критерийлары, алардан файдалануның һәм анализның тулылыгы;
- эшнең күрсәтелгән номинациягә туры килүе, эзлеклелек һәм бәян итүнең ачыклыгы, стиль, бәян итү логикасы, эшнең грамматик дәрәҗәсе, эш структурасының нигезлелеге.

Конкурс проектын бәяләү критерийлары: 0 балл - критерийга минималь туры килү, 5 балл - критерийга максималь туры килү.

Эшне бәяләү буенча иң күп балл - 40 балл.

## 5. Конкурс нәтиҗәләрен ясау һәм җиңүчеләрне бүләкләү

5.1. Конкурста катнашучыларның эшләрен Конкурс комиссиясе карый.

5.2. Конкурс комиссиясе составы Конкурсны оештыручылар арасыннан төзелә һәм Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы боерыгы белән раслана (3 нче кушымта).

5.3. Конкурста җиңүчеләр конкурс проекты белән җыелган балларны кушып берләштерү юлы белән билгеләнә.

5.4. Конкурска йомгак ясау конкурс комиссиясенең йомгаклау беркетмәсе белән рәсмиләштерелә.

5.5. Конкурсны оештыручылар өстәмә рәвештә махсус призлар бирү яки Конкурс таләпләренә туры килмәгән очракта призлы урыннар бирмәү хокукын калдыра.

5.6. Конкурста җиңүчеләр энергия ресурсларының нәтиҗәлелеге һәм экология буенча Татарстан халыкара форумын уздыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан бүлеп бирелә торган акчалар исәбеннән сатып алынган истәлекле призлар һәм дипломнар белән бүләкләнәләр.

5.7. Конкурста катнашучыларның барысы да катнашучы дипломнары белән бүләкләнә.

5.8. Конкурста җиңүчеләрне бүләкләү энергия ресурсларының нәтиҗәлелеге һәм экология буенча Татарстан халыкара форумының Яшьләр көне кысаларында үткәреләчәк.

**Элемтәгә керү өчен мәгълүмат**

6.1. Гаризалар җыюны һәм эшкәртүне «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы энергияне сак тоту технологияләре үзәге» ДАУ мәгълүмат-нәшрият һәм белем бирү эшчәнлеге бүлеге гамәлгә ашыра.

Адрес: 420088 Казан шәһ., Губкин ур., 50, ә/я 131;
тел/факс: (843) 272-99-43, 272-19-21, 272-99-69;
e-mail: cetrt@mail.ru.

Конкурс үткәрү турындагы
нигезләмәгә 1 нче кушымта

**«Без энергия нәтиҗәлелеген сайлыйбыз-2021»**
**яшьләр инициативаларының республика конкурсында катнашуга**
**гаризаның формасы**

**1. Катнашучы турында белешмәләр**

| | |
|---|---|
| Катнашучы Ф.И.О (соңгысы - булган очракта) | |
| Индекс күрсәтелгән почта адресы | |
| Мәгариф учреждениесе | |
| Факультет / Кафедра | |
| Класс/Курс | |
| Элемтә өчен телефон: | |
| E-mail: | |

**2. Конкурс эше турында белешмәләр**

| | |
|---|---|
| Конкурс эшенең исеме | |
| Конкурс эше бирелә торган номинация | *Иск.: номинациянең исеме Конкурс турындагы нигезләмәнең 3 нче бүлегенә туры килергә тиеш* |

**3. Гаризага теркәлә торган документлар исемлеге:**

| № | Документның исеме (битләр/шт саны) |
|---|---|
| *1* | *Мәсәлән: Конкурс эше паспорты (5 бит).* |
| *2* | *Мәсәлән: Эшне тәкъдим итү (10 бит).* |
| *3* | *Мәсәлән: Фотосурәтләр (3данә).* |
| *4* | *Мәсәлән: Видеоролик (1 данә).* |

_*Катнашучының имзасы*_______________*(Ф.И.О)*
*Конкурска җибәрү датасы:* ______________________

## 4. «Без энергия нәтиҗәлелеген сайлыйбыз-2021» яшьләр инициативалары республика конкурсының Конкурс эше паспорты

**1. Конкурс эшенең исеме**

**2. Номинация:**

**3. Конкурс эше аннотациясе** *түбәндәгеләрне үз эченә ала: төп нигезләмәләрне һәм максатларны бәян итү, теманы һәм аның актуальлеген сайлауны нигезләү, әлеге тематика буенча гамәлдә булган тикшеренүләргә кыскача күзәтү.*

**4. Теоретик өлеш** *түбәндәгеләрне үз эченә ала: эшне/технологияне тасвирлау (энергия нәтиҗәлелеге, энергияне сак тоту, энергия нәтиҗәлелеге технологияләре, продукциясе, җитештерү технологияләре, җәмгыятьтә үз-үзеңне тотыш модельләрен үзгәртү, әлеге теманың закон аспектларын камилләштерү, шулай ук аларның гамәлдә булганнарын яисә шундый укларын камилләштерү һ.б.); тикшерелә торган проблема буенча әдәбиятка теоретик анализ.*

**5. Практик өлеш** *үз эченә түбәндәгеләрне ала: эш нәтиҗәләрен куллануның билгеләнешен һәм өлкәсен тасвирлауны; сурәтләрне (сызымнарны, графикаларны һ.б.).*

**6.** Икътисадый нәтиҗәлелекне нигезләү

*- техник юнәлештәге конкурс эшләре өчен икътисадый файда янга калдырылган энергия бәясе (тиешле тарифка тапкырланган энергетика эффекты) буларак бәяләнә, моңа эксплуатация чыгымнарын тотып калу һәм җиһазларны амортизацияләү дә керә.*

*- гуманитар юнәлештәге конкурс эшләре өчен икътисадый файда төрле тикшеренүләр (беренчел, икенчел) нәтиҗәсендә алынган мәгълүматлар, шулай ук Конкурста катнашучы тарафыннан көтелгән нәтиҗәләрнең фаразлары нигезендә бәяләнә.*

**7. Йомгаклау -** *эшнең төп нәтиҗәләре, гамәлгә кертү перспективалары.*

Конкурс үткәрү турындагы
нигезләмәгә 2 нче кушымта

**«Без энергия нәтиҗәлелеген сайлыйбыз-2021» яшьләр инициативалары республика конкурсының Конкурс эшләрен башкаруга таләпләр**

1. Конкурс документларының пакеты электрон рәвештә түбәндәге электрон почта адресына җибәрелә: cetrt@mail.ru (“Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы энергия саклау технологияләре үзәге” ДАУның мәгълүмат-нәшрият һәм белем бирү эшчәнлеге бүлегенә).

2. Эшнең рәвеше: битнең формасы - А4, битләрнең барлык кырлары - 2 см, New Roman Times шрифты, шрифт күләме - 12 кегль, төзелеш ара интервал - 1,5, абзац (кызыл юл/чигенү) - 1 см, эшнең төп текстын тигезләү - киңлеге буенча. Редактор Microsoft Word. Аннотация текстның 1 битеннән артмаска, 1000 басма билгегә кадәр булырга тиеш. Тәкъдим итү: 5-10 слайд, файл форматы - PDF.

Конкурс эшенең төп текстының күләме басма текстның 10 битеннән дә артмаска тиеш.

3. Конкурска заявка һәм конкурста катнашу өчен бирелгән барлык документлар PDF форматында электрон рәвештә бирелергә тиеш. Барлык логотиплар, фотографияләр һәм башка иллюстрацияләрнең аларны JPG форматында (кимендә 300 dpi)матбугат өчен кулланырга мөмкинлек бирә торган рөхсәт булырга тиеш. Шул ук вакытта һәр аерым документ (гариза, презентация һ.б.) аерым битләргә бүленмәскә, ә бердәм файл белән рәсмиләштерелергә тиеш (*Искәрмә: бер документның барлык битләре дә бер файлда булырга тиеш).*

4. Конкурс нәтиҗәләре буенча апелляцияләр кабул ителми.

5. Авторлар  Конкурска тапшырылган эшкә кагылышлы мәгълүматка карата үзләренең тулы җаваплылыкка ия булулары белән ризалашалар. Конкурсны оештыручылар авторлык эшенең эчтәлеге һәм аның закон таләпләренә туры килүе өчен, авторлык хокукларын бозган, товар билгеләрен, фирмаларның исемнәрен һәм аларның логотипларын санкцияләмичә файдалану, шулай ук өченче затларның хокукларын бозу өчен җаваплылыкка ия булмыйлар. Өченче затлардан Конкурс эше эчтәлегенә бәйле дәгъвалар килгән очракта, Конкурсны оештыручылар автор турында булган мәгълүматны бирә, һәм автор мөстәкыйль рәвештә һәм үз исәбенә күрсәтелгән дәгъваларны җайга сала.

Конкурс үткәрү турындагы
нигезләмәгә 3 нче кушымта

**«Без энергия нәтиҗәлелеген сайлыйбыз» яшьләр инициативаларының республика конкурсының Конкурс комиссиясе составы**

| | | |
|---|---|---|
| 1. | МИНИБАЕВ<br>Марат<br>Фәйзрахман улы | Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары - Комиссия рәисе |
| 2. | ӘХМӘРОВ<br>Марат Равил улы | «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы Энергия саклау технологияләре үзәге» ДАУ директоры - Комиссия рәисе урынбасары |
| 3. | МАРТЫНОВ<br>Евгений<br>Васильевич | «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы Энергия саклау технологияләре үзәге» ДАУ директоры урынбасары |
| 4. | КАТКОВА<br>Евгения Игоревна | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының энергияне сак тоту һәм энергия нәтиҗәлелеге бүлеге башлыгы |
| 5. | ЛЕОНОВА<br>Татьяна<br>Викторовна | «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы энергияне сак тоту технологияләре үзәге» ДАУның мәгълүмат-нәшрият һәм мәгариф эшчәнлеге бүлеге башлыгы |
| 6. | МОТЫЙГУЛЛИН<br>Җәлил Нургали улы | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының фәнни-техник сәясәт бүлегенең әйдәүче киңәшчесе (килешү буенча) |
| 7. | ӘХМӘТОВА<br>Ирина Гәрәй кызы | «Казан дәүләт энергетика университеты» югары һөнәри белем бирү ФДБМУнең фәнни эш буенча проректоры (килешү буенча) |
| 8. | ГАПОНЕНКО<br>Гапоненко Сергей Олегович | Казан шәһәренең яшь галимнәр һәм белгечләр советы рәисе, «Казан дәүләт энергетика университеты» югары һөнәри белем бирү ФДБМУнең «Сәнәгать җылылык энергетикасы һәм җылылык белән тәэмин итү системасы» кафедрасы доценты (килешү буенча) |